*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№4 (26)

Гыйнвар-февраль, 2018 нче ел

## Бу санда:

*Гимназия сулышы* 1

*Тормыш дәресләре* 2

*Муса Җәлил эзләре буйлап* 3

*Яшь каләм тибрәтүчеләр мәйданы* 4-5

*Хәтер сандыгы* 6-7

*Яшь шагыйрьләр киләмәйданга* 8



## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Республика олимпиадалары көндәлеге

11 нче б сыйныфы укучысы **Зәфәр Мәҗипов** ике ел рәттән химия буенча "Уңышка юл" республика олимпиадасы призеры булды. Укытучысы В.Г.Семенова.

10 нчы б сыйныфы укучылары **Фәхертдинова Айгөл** һәм **Зиязова Миләүшә** Бөтенроссия олимпиадасының региональ турында биология буенча призер булдылар. Укытучылары Л.Ф.Бариева.

11 нче а сыйныфы укучысы **Эльвина Шамукаева** ике ел рәттән татар теленнән республика олимпиадасында призер булды, быел Эльвина – җиңүче! Бу җиңү аңа Халыкара олимпиадада катнашу хокукы бирә. Уңышлар юлдаш булсын, Эльвина!



### Гимназия укытучылары яңа үрләр яулый



**"Ел укытучысы - 2018"** бәйгесенең муниципаль этабында гимназия укытучылары уңышлы чыгыш ясады. Рус теле һәм әдәбияты укытучысы Ч.А.Хәйруллина беренче, башлангыч сыйныфлар укытучысы А.Р.Гомәрова өченче урын яулады, информатика укытучысы А.Р.Кадирова конкурс призеры булды.

*******



**"Ел сыйныф җитәкчесе - 2018"** кысаларында "Шәхес тәрбияләү" бәйгесендә 7 нче а сыйныфы җитәкчесе Г.Ф.Ямалова Гран-При иясе булды. Ул зона этабында чыгыш ясаячак. 10 нчы а сыйныфы җитәкчесе Г.Р.Бакирова өченче урынга лаек булды.



### Кышкы спартакиада уеннарында

Укытучыларыбыз спортта да сынатмый. Гимназия һәм "Нептун" бассейны җыелма командасы XXVIII Кышкы спартакиада уеннарында волейбол, милли көрәш, мини-футбол, кул көрәше буенча 1 урыннар яулап, гомуми зачетта 908 балл белән 3 нче урында бара. Алдагы этапта да уңышлар телибез! Алга, яңа үрләргә!

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Тормыш дәресләре


Башлангыч сыйныфларда “Тормыш дәресләре” кысаларында Габделкәрим хәзрәт белән гамьле әңгәмә сәгатьләре узды.




Гимназия укучылары “Туган як” музеенда музей-дәресләрдә катнаштылар.



Барлык сыйныфларда “Әтиәнием һөнәре” темасы астында ата-аналар катнашында дәресләр узды.



Гимназиянең 8-10 нчы сыйныф укучылары Әфганстанда һәлак булган солдатларны искә алу митингында катнаштылар.



Ватанны саклаучылар көне алдыннан 10 нчы а һәм б сыйныфы укучылары Әфган сугышы ветераны Галиев Зиннур Дамир улы белән очраштылар.



Профориентация буенча максатчан эш бара. Гимназиядә югары уку йортлары вәкилләре укучылар белән очрашты.



Башлангыч сыйныф укучылары салкын кышның кырыс шартларын җиңеләйтү өчен, гимназия территориясендәге агачларга җимлекләр ясап элделәр. Районыбызда “Экология елы” кысаларында башкарылган бу изге гамәл дәвамлы булсын иде.



Кышкы табигатькә экскурсия, тауда чана шуу – балаларның иң яраткан шөгыле. Туган якның саф һавасы, ап-ак кары җанга шифа, тәнгә дәва бирә.



### Дәрестән тыш эшчәнлек

Гыйнвар аенда география-башлангыч сыйныфлар-тарих атналыгы узды. Атналык кысаларында ачык дәресләр, мастер-класс, класстан тыш чаралар үтте.

Февраль аенда математика-химия-биология-физика-информатика фәннәре атналыгы бара. Фәннәрне интеграль укыту буенча укытучыларның тәҗрибәсе өйрәнелә, мавыктыргыч класстан тыш чаралар оештырыла.

Хәрби-патриотик айлык кысаларында 8 нче б сыйныфы укучысы Абдуллин Ранэль һәм 9 нчы а сыйныф укучысы Хайбрахманова Айзилә ату ярышларында призер булдылар.

Башлангыч сыйныф укучылары өчен “Үлемне җиңгән шагыйрь” темасы астында китапханә дәресләре узды. Муса Җәлил әсәреннән төзелгән китап күргәзмәсе эшләде, Г.М.Солтанова укучылар белән әдәби викторина уздырды.


Башлангыч сыйныф укучылары ел дәвамында проект эшләре башкаралар, аларны яклау дәвам итә. Иң кызыклы проектлар уку елы ахырында бәя алачак.

Халыкара туган тел көне кысаларында 5-7 нче сыйныф укучылары катнашында квест-уен оештырылды. Татар, рус, инглиз телен камил белүне күздә тоткан әлеге проектны тормышка ашыручылар – 10 сыйныф укучылары. 7 нче б сыйныфы командасы җиңү яулады.

Гимназия укучылар үзидарәсе студентлар белән очрашу кичәсе, «Гашыйклар көне»нә багышланган тематик дискотека оештырды.

Һәр ел саен уздырылучы «Искиткеч вожатый» конкурсында биел 8 нче б сыйныф укучысы Латыйпова Язилә “Иң үзенчәлекле” номинациясендә җиңүче булды.

# МУСА ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП



Муса Җәлил (1906-1944)

**Җәлил батырлыгын герләр, таулар һәм мәрҗәннәр белән бәһаләрлек түгел.**
***Вахит Имамов***

*Һәр халыкның милли-мәдәни йөзе, аң үсеше дәрәҗәсе, беренче чиратта, энҗе бөртегедәй балкыган әдәби җәүһәрләре, мактанычын, горурлыгын, үткәнен һәм киләчәген билгеләгән иҗади мирасы белән бәяләнә. Олы, бай һәм чал тарихлы, Тукай, Дәрдемәнд, Такташ һәм Туфанлы XX йөз татар әдәбиятын үлемсез шигырьләре белән мәңгеләшкән Муса Җәлил исеме дә бизи. “Моабит дәфтәрләре” белән милли шигърияткә дөнья киңлекләренә чыгарган, кыска гомерендә үзеннән соңгы буыннарга үлмәс иҗат калдырган, яшәү мәгънәсен туган халкына хезмәттә күргән, аны батыр йөрәкле, үлмәс итеп танытkан, Ватан азатлыгы хакына газиз җанын биргән, язмыш сынауларына бирешмичә, үлемен батырларча кабул иткән көчле рухлы шәхес ул.*



Патриотик айлык кысаларында гимназиядә Муса Җәлилнең 112 еллыгына багышлап, «Муса Җәлил эзләре буйлап» исемле квест-уен уздырылды. Проектны 10 нчы а һәм б сыйныфы укучылары әзерләде һәм тормышка ашырды. Квест-уенда 7-8 нче сыйныф укучылары катнашты. Волонтерлар командаларны әзерләде. Биремнәр алты тукталыш рәвешендә башкарылды. Һәр этап ныклап уйланылган. Җитди әзерлекле кураторлар командаларны тукталышларда каршы алды, биремнәрне бәяләде. Укучыларга “Серле бүлмә”, “Шигырьне төзе” тукталышлары, пазллардан картинка җыю аеруча ошады. Укучылар Муса Җәлил иҗаты һәм тормыш юлы турында белемнәрен күрсәттеләр, өстәмә мәгълүматлы булуларын исбат иттеләр. Ярыш – ярыш инде. Җиңүчеләр дә, сынатучылар да булды: 8 нче в сыйныфы укучылары беренче урын, 7 нче б, 8 нче б икенче урын яуладылар. 8 нче а сыйныфы өченче урында калды.









**Җиңүче команда -**
**8 нче в сыйныф укучылары**









## ЯШЬ КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘР МӘЙДАНЫ

### Мөслим гербындагы Курайчы егет рәсеме турында легенда



Ык елгасы Идел кебек киң җәелеп аккан, Иске Авыл таулары күкләргә ашып торган, Наратасты урманнарында аюлар булган заманнарда яшәгән, ди, булган, ди, табигать тавышларын аңлый торган бер егет. Егет башкалардан сәерлеге белән аерылып торган. Ул көн буена урманда, болыннарда йөри. Үләннәр шаулавын, агачлар серләшүен, елга агышын тыңлый торгач, кошлар-киекләр телен аңлый торган егеткә әверелә. Башкаларга үзе белгәннәрне, тойганнарны сүзләр белән аңлатып бирә алмавы өчен бик борчыла.

Бервакыт тау битендә үскән биек балтырган үләненнән төрле озынлыкта көпшәләр кисеп ала. Җил уңаена басып торганда, бу көпшәләр эчендә һава йөри башлый һәм егет аларның төрлесе төрле тавыш чыгарганын абайлап ала. Иреннәренә тидереп, буш көпшәләргә өреп карый. Табигатьнең могҗизалы тавышларын төрле озынлыкта, төрле юанлыктагы көпшәләр ярдәмендә чыгарырга өйрәнә егет. Аннары төрле урыннарына уемнар куя. Җиде, сигез, тугыз, ун тотамлы курайлар шулай итеп барлыкка килә.

Кич җиткәч, егет кулына136 кураен ала. Бөтен тирә-якны гамьләндереп, үзенең моңлы көйләрен уйный икән. Тирә-якта яшәүчеләр үзләре дә бик моңлы, җырга-биюгә һәвәс халык икән. Бүгенге көндә дә Мөслимлеләр турында сөйләгәндә “Җырга-моңга бай Мөслим ягы” дип сөйләргә яраталар бит.

Бер кичтә, шулай моңланып курайда уйнап утырган вакытта, кинәт давыл күтәрелгән. Кап-кара өермә килеп, егетне күтәреп алып киткән. Авылдашлары бик борчылганнар, егетне бик озак эзләгәннәр. Давыл килгән саен, куркуга кала торган булганнар. Тәмам өметләре өзелгәч, егетнең истәлеген мәңгеләштерү өчен, үз гербларына Курайчы егет рәсемен куйганнар. Шулай итеп, Мөслим авылы гербында Ык дулкыннары фонында курай уйный торган егет рәсеме пәйда булган.



Мөслим авылында “Курай паркы” барлыкка килүе дә очраклы түгел, әлбәттә... Давыл күтәреп киткән Курайчы егет, бик күп гасырлар үткәч, вакыт машинасына утырып, кабат Мөслимгә әйләнеп кайткан. Авыл читендәге сәнгать мәктәбе янындагы буш мәйданчыкка килеп төшкән егет. Туган җирләренә кабат кайтуына сөенеп, курайда уйнап җибәргән. Үз авылы аңа җәннәт почмагы кебек тоелган. Хисләренә ирек биреп, өздереп уйнаган да уйнаган егет. Курай моңнары Мөслим халкын бу урында парк төзергә рухландырган. Шулай итеп, барлык мөслимлеләр өчен рәхтләнеп ял итү урыны барлыкка килгән.

***Әдилә Бәдертдинова,***
***5 нче а сыйныфы укучысы***

### Мәтрүшкәле чәй турында легенда

Бер агайның хатыны авырып китә, бөтенләй урыннан тора алмый башлый. Баласы сизмәсен дип, атасы кызын урманнарга, тауларга алып чыга, сахраларда йөртә икән. Иске Авыл



тауларының аланнарында шифалы җиләк җыеп как киптерәләр, Ык буе әрәмәләрендә бөрлегән, шомырт, балан, камырлык җыялар икән. Әтисе учак ягып чәй кайната, карлыган яфраклары салып, хуш исле чәй белән кызын сыйлый икән.

Көннәрдән бер көнне әтисе, учак ягып, казан асып, чишмә суын кайнатырга утырта, үзе йокымсырап китә. Кызы якын-тирәдә чәчәкләр җыеп йөри. Казанда суның шаулавын ишеткәч, кыз йөгереп килә һәм ялгыш кына кулындагы чәчәкләрне кайнап торган суга төшереп җибәрә. Болынга хуш ис тарала. Кайнаган суны әрәм итмиләр, эчеп



карыйлар. Аның шифалы тәэсирен аңлап алалар. Вак кына зәңгәр чәчәкләрне җыеп, авылга алып кайталар. Кызы мондый чәйне көн саен әнисенә эчертә. Зәңгәр чәчәкле шифалы үлән чәе ананы аякка бастыра. Кыз көн саен әнисен: “Мә, крушкә”, - дип сыйлап чәй эчертә торган була. Тора-бара бу үләнне мәтрүшкә дип йөртә башлыйлар. Мөслим ягы урманнарында мәтрүшкә күп очрый. Шифасы булсын өчен, аны дөрес итеп җыярга кирәк.

***Румия Бакиева,***
***5 нче а сыйныфы укучысы***

## ЯШЬ КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘР МӘЙДАНЫ

### Ык елгасы атмасы каян килеп чыккан?



Бик борынгы заманнарда, әле Мөслим авылы урынында бер йорт та булмаганда, чал башлы Урал тавы итәгеннән үк башланып, аска таба агып төшүче инешләр, ташкын сулы чишмәләр берләшеп, зур елга булып ага башлаганнар. Тирә-якны кешеләр ерып чыкмаслык куе әрәмәләр каплап алган була. Биек тауларда төз наратлар, меңьяшәр имәннәр үскән.

Таулардан шаулап төшкән мул сулар, кочле агым тәэсирендә, бормаланып-бормаланып агалар икән. Елганың бер ягы бик текә ярлы, икенче яры сөзәк булган. Яз җиткәч, ташу вакытларында елга ярларына сыя алмаган: яшел болыннарга, үзәннәргә җәелгән. Су чигенгәч, бу урыннарда уңдырышлы кара туфрак җыелып кала икән. Кешеләр мондый җирне бик тиз күреп алганнар һәм беренче булып шундый урыннарга килеп утырганнар.

Һәр яз саен елга ташый, йортларны, хәтта атларны агызып алып китә икән. Бу хәл күчеп утырган кешеләрне борчуга сала. "Ыкы, дөрес эшләмәдек, елга ел саен авылны болай басып китсә, башка җиргә күчәргә кирәк булыр," – дип сөйләшәләр икән картлар. Аптырап утырганда әйтелгән "ыкы" дигән аваз елганың исеменә әверелеп киткән, һәм ул бүген дә Ык дип йөртелә икән.

***Шамил Усманов, 5 нче а сыйныфы укучысы***

### "Курай паркы" турында легенда

Табигатьнең иң гүзәл почмагы дип саналган Мөслим авылы явыз көчләр аркасында танымаслык хәлгә төшә. Авылның хезмәт сөючән кешеләре ялкауга әверелә. Авыл халкын битарафлык чире биләп ала. Бу йогышлы чир бик тиз тарала, аны берничек туктата алмыйлар.

Мөслимдә чүп үсеп утырган ташландык урыннар бик күп булган. Кешеләр анда атлар, бозаулар, сыерларын бәйләп куялар, сарыклар, кәҗәләр иркендә йөри торган булган. Урамнарда кәҗәләр кимергәннән калган агачлар, үсә алмыйча, кешеләргә рәнҗеп утырганнар.

Авыл читендә генә яшәүче бер гап-гади гаиләдә бик үзенчәлекле бер бала туа. Кечкенәдән үк кешелекле, башкалар турында кайгыртучан, кече күңелле була ул. Нәрсә генә эшләсә дә, матур итеп, сыйфатлы итеп башкарырга тырыша, эшләгән һәр эшен аеруча үҗәтлек белән эшли торган була. Аны, әлбәттә, аңламыйлар, хәтта "сәер бала" дип карыйлар. "Дөньяны матурлык коткарыр!" – дип сөйләгән сүзләренә дә шикләнеп карыйлар.



Бу бала егет булып үсеп җитә. Кич җитсә, кураен алып, авыл читендәге болынлыкка чыгып китә торган була. Күңеленә җыелган моңнарын курай көпшәсенә өреп, үзенең сагышларын таратырга күнегеп китә. Аның моңыннан



чишмә сулары сафланып китә, кошлар сайраудан туктап тора икән. Көянтә-чиләкләрен элеп суга баручы кызларның аяк атлаулары җиңеләя, бишектә йоклый алмый яткан сабыйлар татлы йокыга тала икән. Бу сәер егетнең "дөньяны матурлык коткарыр!" дигән сүзләренә инде шикләнеп карамыйлар, чөнки аларның күз алдында матур үзгәрешләр чоры башлана. Кешеләрнең күңеле матурлыкка тартыла башлый. Мөслим халкы явыз көчләрдән арына һәм үзләре яшәгән тирәлекне гүзәл җәннәт почмагына әверелдерү эшенә керешәләр.

Егет курай уйный торган ташландык җирдә искитмәле ял урыны - "Курай паркы" һәм "Балалар сәнгать мәктәбе" төзелә. Хәзер ул урын барлык Мөслим халкы һәм кунакларның яраткан ял урынына әверелде.

***Закирова Айназ һәм Айгильдин Андрей, 5 нче а сыйныфы укучылары***

## ӘДӘБИ СӘХИФӘ

### ХӘТЕР САНДЫГЫ

*Бабам истәлегенә багышлыйм*



***Кашапова Илүзә,*** *11 нче а сыйныфы укучысы*

Төннең караңгы пәрдәсен күтәреп, кояш җиһанга күз салды. Бар тереклек татлы йокыда. Кояш беренче нурларын куначада йокымсырап утырган әтәчкә юнәлтте. Әтәч, кояшның җылы нурлары төшүгә, кикриген турайтып, күкрәген кабартып, “кикри-кү-ү-үк” дип, быргысын кычкыртып, таң атуын хәбәр итте. Кояш нуры умарта авызында сакта торучы бал кортларына төште. Алар, безелдәп, йоклап ятучы башка бал кортларын уяттылар. “Умарта шәһәрчеге” гөж килде. Кайсыдыр аллы-гөлле чәчәкләрдән бал җыярга кузгалды, кайберәүләре гаиләдәге эшләр белән кайнаштылар.

Төне буе йоклый алмыйча борсаланып яткан Фатыйма, торып, сөйләнә-сөйләнә тышка чыкты:

- И, Аллаһемның рәхмәтләре белән бүген дә таңны аттырдык. Барчабызга да саулык-сәламәтлек, илләргә иминлек, җаннарыбызга тынычлык бир, Ходаем, - дип, догаларын укый-укый, бакчада рәт-рәт булып тезелеп утырган умарталарын күзләде. - И, Ходайның рәхмәте төшкерләре, уяндыгызмы, барчагыз да исән-имин тордыгызмы?

Фатыйманың күзе бакча түрендә шау чәчәктә утыручы карт алмагачка төште. Алмагач-чордаш бер якка янтайган, ботаклары салынып төшкән. Алмагачның кәүсәсен йомшак куллары белән сыйпап, хәтер йомгагын сүтте. ...Фатыйманың бу нигезгә килен булып төшүенә дә шактый гомер узган. Галиулласы аны күрше авылдан җитәкләп алып кайтты, әнисе каршына китереп бастырды. Аның әнкәсе фәрештәгә тиң иде. Өстендә чын татар хатын-кызларына гына хас ак күлмәк, зәңгәр бәбәй итәкле алъяпкыч, башында кирәч кебек ак яулык иде. Изге күңелле иде аның бианасы. Үз әнкәсенә тиңләп яратты ул аны. Сердәшләр булып, тормышның авырлыгын да, шатлыгын да бергә җигелеп тарттылар. Өйдәге барлык көндәлек эшләр бианасы Фәрхежиһан карчык җилкәсенә төште. Көнне төнгә ялгап, Галиулласы белән бергә-бергә кырда тимер атларын иярләп җир сөрделәр, иген чәчтеләр. Итәк тулы балаларын карап, кайнар ашын пешереп, иренең эштән кайтканын көтеп өйдә генә ятасы да бит. Юк шул, заманасы ул түгел иде. Галиулласы белән беррәттән, аннан калышмыйча, гектар саны үтәде. Заманасы авыр дип тормадылар: лачындай батыр, эшкә нык алты ул, карлыгачтай кара, сөйкемле, бар яктан да уңган, булган ике кыз үстерделәр. Менә бу алмагачларны да тормыш коргач та утыртканнар иде. Менә бу кечкенә генә “умарта шәһәрчеген” дә бергә тергезделәр.

Фатыйманың ире бик каты авырып китте. Дәва эзләп йөрмәгән җирләре, шакымаган ишекләре калмады. Газап чигеп йөрүләрнең нәтиҗәсе булып, кочак-кочак дарулар, йокысыз төннәр генә кала бирде. Озак газапланды карты бума ютәл белән. Фатыйма Галиулласына сәламәтлек сорап, көн дә Ходайга ялварды.

Бер көнне гәҗит-журналлар актарып утырганда “Бал - җитмеш төрле авыруга дәва” дигән мәкаләгә күзе төште. Мәкаләнең бер өтерен, ноктасын да калдырмыйча укып чыкты Фатыйма. Шуннан соң Галиулла белән Фатыйма умарта асрарга дигән ныклы карарга килделәр. Умарта асрау бик нәзакатьле, четрекле шөгыль. Бал кортлары - төгәллек, чисталык, тәртип ярата торган җан ияләре. Аларны вакытлы-вакытсыз борчырга да ярамый. Болытлы, артык эссе көннәрдә кортлар янына якын килмәвең хәерле. Юкса, күрмәгәнеңне күрсәтәчәкләр.

Галиулла күкрәген тутырып умарта исен сулады. Ходайның рәхмәте, шушы кечкенә генә җан ияләре аңа шифа бирде. Нигъмәтулла генә эшләмәде ул кортлар ясаган чималдан: тома балавызны ак май белән су парында кайнатып та, ачы торманы бал белән бутап та эчте, төнәтмәләр ясады. Корт чагулар, бал шифасы Галиулланы, чыннан да, тулысынча савыктырды. Бик тату яшәделәр алар Галиулласы белән. Артык сүз сөйләшмәделәр, бер-берсен күз карашыннан аңлый иделәр. Менә хәзер Фатыйма берьялгызы. Сөекле Галиулласы да, Фәрхежиһан карчык та бакыйлыкта. Фатыйманың җыерчык кунган битләреннән күз яшьләре тәгәрәште.

Каяндыр кинәт кузгалган җил аның чал чәчләреннән, яшьле битләреннән йомшак кына сыйпап үтте. Фатыйма, уйларыннан арынып, әкрен генә өенә таба атлады.

Капка ачылып китте. Май кояшыдай балкып, Айзиләсе кереп килә икән. Яраткан оныгына һич кенә дә күз яшьләрен күрсәтергә ярамас. Фатыйма тирән итеп сулыш алды да оныгына таба атлады.

******

Айзилә китапларын барлап букчасына салгач, көзге алдында бер бөтерелеп алды да, ашыга-кабалана тышка чыкты. Көн шундый матур, май кояшы, әниләр кочагы җылысын чәчеп, бар җиһанны алтын нурлары белән иркәли. Айзилә болдырда кояш җылысында изрәп яткан Сорыкайны иркәләп:

- Ай, наянкай, кояшта эреп югала күрмә тагы, тычканнарны кем тотар, - дип йөгерә-атлый урамга чыкты. Анда аны күрше кызы Айсинә көтеп тора иде.

- Озак көттеңме?

- Сәлам, дускай. Ай-яй озак йоклыйсың, күршекәем. Күр инде, “сары тәгәрмәч” күкнең яртысына җитеп килә, - дип хәйләкәр генә күзләрен кысып елмайды. – Әйдә, ашыга төшик, автобуска соңга калмыйк.

Кызлар күрше районга йөреп укыйлар. Үз мәктәпләре дә зур, якты, югыйсә. Финанс кытлыгына сылтап, мәктәпләрне “кыскартып” бетерделәр дә кызлар көн дә иртән букчаларын асып, автобус тукталышына чабалар.

Менә бүген дә кызлар, җитәкләшеп, көлешә-көлешә тукталышка элдерделәр. Тукталышны ак фәрештәләр сырып алган диярсең. Кызлар барысы да пар бантик, ак алъяпкычлардан, егетләр ак күлмәк, кара чалбарлардан. Шулай булмыйча соң, бүген соңгы кыңгырау бәйрәме! Авыл башыннан сары автобусның килгәне күренде. Кызлар күз карашы белән автобусны тукталышка кадәр озаттылар. Шау-гөр килеп, салонга үттеләр. Кыска гына маршрут дәвамында укучылар кем кайда ял итәргә планлаштырулары турында берсеннән берсе уздырып хәбәр итәргә ашыктылар. Айзат, Ранис җәйге лагерьга, Алсу белән Фәйрүзә шәһәрдәге апаларына кунакка барачак, Илдар белән Алмаз авылда әтиләренә булышалар... Ә менә Айзилә, һичшиксез, авылга – сөекле әбисе янына барачак.

Автобуска ничек шау-гөр килеп керсәләр, шулай ук коелып та беттеләр. Һәркайсы үз классына юнәлде. Айзилә классташлары белән бергә укытучылары янына ашыкты. Укытучы апа зәбәрҗәт тигез тешләрен җемелдәтеп, кочагын җәеп, укучыларын каршы алды. Кочагы резин булса, билләһи, 25 укучыны берьюлы кысып кочар иде. Укучылар апаларын бик тә яраталар. Апалары алар өчен яхшы киңәшче, сердәш, белем сукмакларын яктыртучы маяк та. Әнә укучыларын бер йомгакка җыйнаган да, җәйге ялларга таралганчы дип, үгет-нәсыйхәтләрен, киңәшләрен бирә...

Уку елы тәмамлануын белдереп, кыңгырау чыңлады. Сау бул, мәктәп!.. Исәнме, җәй! Айзилә бүген үк әнисенең туган авылына юл тотачак!

*****

Айзилә, өс-башларын алыштырып, чәйләп алды да ишек алдына чыкты. Читлектән азат итүләрен көтеп арган йомшак сары йомгаклар көтәләр иде аны. Үрдәк бәбкәләре “кайда югалып йөрдең бу кадәр озак” дигәндәй, канәгатьсезлекләрен белдереп шаулашып алдылар да, читлек ишеге ачылуга, яшел чирәмгә сибелделәр. Әнкә үрдәк, балаларын тилгәннән саклагандай, канатларын җәеп, бәбкәләрен җыйнап тотарга тырышып карады, ләкин файдасыз. Ирек төмен сизгән бәбкәләр әнкәләрен тыңларга да теләмәделәр, “пи-пи-пи” килеп, кайсыдыр сусыл чирәм чүпләде, кайсыларыдыр чебен-черки артыннан йөгерештеләр.

Әшеннән канәгать калып, кыз, чирәм өстенә җәймә

## ӘДӘБИ СӘХИФӘ

төшәп, сузылып ятты. Шуны гына көткәндәй, болдырда утыручы песи балалары Сорыкай белән Каракай аның янына елыштылар да үзләренә генә хас моңлы көйләрен сузып җибәрделәр: "Мы-ы-р-р, мы-ы-р-р...".

Күк йөзе зәп-зәңгәр. Шул зәңгәр киңлектән ашыкмыйча, талгын гына болыт-атлар йөзә. Их, шул атларның куе, бөдрә ялларына тотынырга да илне гизәргә иде...

Матур хыялларын әнкә үрдәкнең хәвефле тавышы бүлде. Айзилә торып утырды. Ишегалды уртасында башын күккә кырын салган әнкә үрдәк кенә басып калган иде. Бәбкәләр кайсы кая качып өлгергәннәр. Айзилә күк йөзендә эленеп торган тилгәнне абайлап алды. Күр син аны, нинди оста аучы! Канатларын җилпемичә ничек шулай озак тора ала икән? Табигатьнең ике могҗизасы, ике әнкә кош: берсе - нәниләрен хәвефтән саклап калу өчен дошманына, ә икенчесе – балаларын ачлыктан саклап калу өчен корбанына ташланырга әзер. Гаҗәп: икесе дә балалары – дәвамчылары гомере өчен көрәшәләр. Айзиләнең күңелен Ана турында шундый уйлар биләп алды.

*****

Ул арада әниләре дә эштән кайтып җиттеләр. Айзилә тиз генә әйберләрен җыйнады да машинага чыгып утырды. Машина әкрен генә үргә үрмәли башлады.

Айзиләләрнең авылы бик матур җиргә урнашкан. Авылны бүлеп, ике кечкенә инеш чылтырап ага. Җәен инеш буенда казлар коенса, кышын бала-чагалар, чыр-чу килеп, тимераякта шуалар, кәшәкә сугалар. Тау башына менгән саен, авыл уч төбендәге кечкенә әкияти сарайга охшап кала. Әнә авыл горурлыгы булган Имәнәй тавы күкрәген киереп, куеныннан челтерәп аккан көмеш сулы чишмә моңына күмелеп утыра. Әнә диңгез кебек җәйрәп яткан очсыз-кырыйсыз иген басулары, яшел чапаннарын талгын җилдә җилфердәтеп утырган серле карурман. Урман җиләк-җимешкә бик бай. Кура җиләге, балан, шомырт, камырлык дисеңме - барысы да бар. Җыеп кына өлгер. Аланында җир җиләге, сирәк каен арасында каен җиләге. Алан итәгенә утырган килеш кенә, куз ачып йомганчы чиләк тутырып җиләк җыясың.

Авылга якынлашканда, Айзиләнең йөзе уйчанланып китте. Быел авыл үзгәрдеме икән? Дуслары, туганнары әле кайтып җитмәгәндер. Ә узган ел җәйге ялга кайтканда капка төбе умарта күчен хәтерләтә, бала-чага тавышыннан гөж килеп тора иде. Айзилә узган җәй истәлекләренә чумды...

Айзиләнең әнисе ишле гаиләдә туып-үскән. Әби белән бабай бер дә куркып тормаганнар. Лачындай батыр, эшкә нык алты ул, карлыгачтай кара, сөйкемле, бар яктан да уңган, булган ике кыз үстергәннәр. Әби белән бабай - авылда иң бай кешеләр. Шулай булмыйча ни! Сигез бала, 21 онык зур байлык түгелмени?!

Ишегалдына тәтен, балавыз исе таралган. Димәк, әби белән бабай умарта тирәсендә кайнашалар. Бабасы оста умартачы да әле Айзиләнең. Лаеклы ялга чыккач, кул кушырып утырмаган, балаларыбыз, оныкларыбыз татлы балдан авыз итсеннәр, авырмасыннар дип, умарта үрчеткән. Әз генә төчкерә башласаң, әби:

- И Ходаем, салкын тидердеңме әллә? - дип, хәзер бер калак бал, чәшкегә җылы сөтен салып йөгерен килә дә: "Мә әле, алтыным, кабып җибәр. Бал 70 төрле авыруга дәва ул, авыруыңны юып төшерер," – дип, баллап сөт эчертә. Чыннан да, әллә балның шифасы тия, әллә әбинең куллары шифа була - сәламәтләнеп китәсең.

Таң беленүгә, әби, бабай үзләренең кечкенә "фазенда"ларына ашыгалар. Бабай әйтмешли, кортларны көн сүрүендә карарга кирәк. Көн кыздыргач, кортлар үзләрен борчыганны бер дә яратмыйлар. Умарталарны бер кат тикшереп, барлап чыккач, әби өйгә ашыга. Оныклар торганчы, чәй куеп, коймакны өлгертергә кирәк. Иртәнге аш әзер булгач, бабай оныклары янына керә дә:

- Кара әле син бу бәләкәй кетмерләрне, һаман йоклап яталар. Кояш малайлары көлә бит сездән, - дип, елмаеп, соклану катыш ярату хисләре белән оныкларына эндәшә. Оныклар ике әйтереп тормыйлар, алар торуга бабай сюрприз әзерләп куйганны беләләр: кем нәрсә ярата - рәхим итеп аша гына. Әбинең табада кызарып пешкән коймаклары, кәрәзле бал, тәм-томнар.

Иртәнге ашны ашагач, Айзилә бакчага чыкты. Бакчада өйгә ошаган кечкенә генә сарай бар. Җәй көне бабасы шунда - умарталары янына "башка" чыга. Сарай эчендә ятып



ял итәргә сәкесе, утырып тамак ялгарга өстәле, хәтта һава торышы, көндәлек яңалык белән таныштырып торучы радиосы да бар. Айзилә бабасының умарта караганын шул "офис"тан күзәтеп торырга ярата. Бабасы һәр умартаны үзенә хас тәртип белән карый. Кортлар кәрәзләрне бал белән тутырып балавыз белән сылаганнармы? Үрчем бармы? Бал кортлары "эш вакытында безне комаучалап, бимазалап йөрмәгез әле" дигән кебек, бабайны төрле яктан бәргәлиләр. Тырышып-тырышып та, "сөңге"ләрен эшкә җигә алмагач, бабайның кулындагы кәрәзне сырып алалар.

- Әй, уңгырларны, каягыз әле, - дип, каз канаты белән кортларны умартага сыпырып төшерә.

Җиңелүгә дучар булган бал кортлары "бабай белән бәхәсләшеп булмый инде, барыбер үз дигәнен эшли" дигән кебек, кабат бал җыярга ерак сәфәргә чыгып китәләр. Кызык. Кечкенә генә җан ияләре ничек шундый зур эш башкаралар икән? Бал җыялар, кәрәзгә тулган бал түгелмәсен, дип, өсләрен балавызлыйлар. Әле балавызны да үзләре ясыйлар бит! Болар кыз өчен сер булып кала бирә.

Умарта бакчасында шундый рәхәт. Бал кортларының гөжләве җанга дәва, күңелгә тынычлык бирә. Гүя алар сихри уен коралы кылларын чиртәләр. Мең төрле сорауга җавап эзләп, сихри моңга уралып, кыз йоклап киткәнен сизми дә калды.

*****

Әбисе белән бабасы янына җәй саен каникулга кайтасы килүе бер дә юкка түгел шул. Аның тәҗрибәле картлардан тормышка өйрәнеп каласы килә. Көннәрдән бер көнне аларны югалтудан коты чыга. Картларның үзенә карата аерым бер җылы мөнәсәбәтен сизә ул. Әнә ич, әбисе ничек итеп назлы тавышы белән иркәләп эндәшә. Айзиләнең тамырларында аның каны ага, әби-бабасының өметен аклап, аларның эшен дәвам итүче итеп күрә ул оныгын. Айзилә дә шуны бөтен йөрәге белән аңлый иде.

Үткәндәге уйларына чумып барып, машинаның авылга килеп керүен сизми дә калган икән Айзилә. Хәтер сандыгындагы иң якты истәлекләреннән аерылып торырга туры килде, чөнки әнисенең туган нигезенә – әби-бабасы йортына килеп тә җиткәннәр иде. Биек карт алмагачка сыенып утырган сап-сары буяулы, җыйнак кына йорт аларны урам якка киң итеп ачып куелган яп-якты тәрәзәләре белән каршы алды.

*****

Бабасының вафатын бик авыр кичерде Айзилә. Ул көннән соң тормыш "бабай исән чакта" һәм "бабайдан соң" дигән ике чакка аерылды. Капкадан кергән вакытта Фатыйма әбисенең карт алмагач янында яшьләрен сөртеп алуын күргәч, кызның нәни йөрәге күкрәк читлегеннән атылып чыгардай итеп тибә башлады. Бу җәйдә Айзилә, һичшиксез, әбисенең терәге булыр. Бабасыннан күргән, өйрәнгән серләрне бергәләп искә төшерерләр. Бакчадагы умарталар әүвәлгечә күңелле итеп гөжләр, тирә-якка тәтен исе катыш балавыз, яңа суыртkan бал исе таралыр. Айзиләнең хәтер сандыгында бабасының һәр әйткән сүзе, һәр хәрәкәте, һәр ымы, һәр киңәше саклана әле.

## ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘР КИЛӘ МӘЙДАНГА



**Хәбибуллина Лиана,**
7 нче б сыйныфы укучысы

### Татарстан – минем республикам

*Минем илем, туган җирем,*
*Ул бит миңа бер генә.*
*Туган илем, туган җирем,*
*Бул син мәңге гөл генә!*

*Болыннарда йөрим җәен,*
*Саф һаваларын иснәп.*
*Кырда гөрләп үссә иген,*
*Пешәчәк күмәч, икмәк.*

*Туган җирем бик кадерле,*
*Бик матур һәм сөйкемле.*
*Якты йөзле, җылы нурлы*
*Таң кояшы шикелле.*

*Еракларга китсәм дә,*
*Сагынмыйча торалмам.*
*Татарстан – республикам!*
*Алсуланган багалмам!*

### Татлы сүздән җан эри

*Йомшак телле, тәмле сүзле*
*Кыз булу җаен беләм.*
*Матур, ягымлы сүзләрнең*
*Тылсымлы көчен тоям.*

*Тәмле телем белән җайлап,*
*Сихерлим әбиемне.*
*Татлы сүземне кызганмыйм -*
*Сөендерәм әнине.*

*Әниемә – "әнкәем" дим,*
*Әтиемә – "әткәем".*
*"Гөлкәем" дим гөлләргә,*
*"Пескәем" дим песигә.*

*Яхшы сүздән эрегәннәрен*
*Күргәнегез бармы соң?*
*Йомшак сүзне кызганмагыз,*
*Телегез арымасын.*

### Бабаем

*Бабай озын гомер кичкән,*
*Карт ул үзе.*
*Ләкин һаман көлеп йөри,*
*Нурлы йөзле.*

*Бабаемны шатландырыйм –*
*Бер шигырь язам.*
*Ходай миңа әйтеп тора,*
*Барысын алдан.*

*Бәләкәй генә булсам да,*
*Гел үсеп барам.*
*Бабаемнан һәрвакыт*
*Мин үрнәк алам.*

*Сәламәт бул, озак яшә,*
*Минем бабаем.*
*Теләгемне кабул итсен*
*Берук Ходаем.*

### Интернет-балалар

*Хәзер шундый замана –*
*Ул чир бар һәр балада.*
*Ата-анага – "ай-һай!",*
*Ә балаларга – Wi-Fi.*

*Әби-бабай өйрәтә:*
*- Син, кызым, укы китап!*
*Ә мин аны ишетмим,*
*Миңа кирәк тик Wi-Fi.*

*- Чапма, тавышланма,- дисәң,*
*Мине туктатып булмый.*
*Каршыма компьютер куйсаң,*
*Инде торгызып булмый.*

*Бу чир туа һәркемдә,*
*Борчылмасын беркем дә.*
*Кайгырмагыз, әниләр:*
*Без – Интернет-бәбиләр!*

### ТАБЫШМАКЛАР

*Компьютерның туганы ул,*
*Әмма аннан кечерәк.*
*Күтәреп барасың килсә,*
*Бик уңайлы һәм кирәк.*

******

*Көне буе уйнасаң да*
*Уйнап туя алмассың.*
*"Бер минутка утырам," – дип*
*Утырсаң тора алмассың.*

******

*Хәзер бөтен кеше дә*
*Ансыз, бәлки, торалмас.*
*Тик кайбер кешеләрдә*
*Бөтенләй дә булалмас.*

********

*Телефоннан зуррак ул,*
*Компьютердан кечерәк.*
*Кулланыр өчен уңайлы,*
*Аның исеме кирәк.*

*P.S. Табышмакларның җавапларын электрон адрес буенча кабул итәбез.*

**ТЫЛСЫМ+**
Гыйнвар-февраль, 2018 нче ел
**Мөслим гимназиясе укучылары газетасы**

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректорлар:** Шамукаева Эльвина, Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Салихова Динара, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Шарифуллин Заһир
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym